# Тема: Кызыклы мәсьәләләр чишү»

- Уен 3-4 класс укучылары арасында математика атналыгында оештырыла.

# Уен барышы:



1. Оештыру
2. Уенның темасын һәм максатын аңлату
3. Мәсьәләләр чишү
4. Җыйнүчеләрне ачыклау
5. Бүләкләр тапшыру

# Максат:

укучыларны уйлый һәм фикерле белергә, мәсьәләләрне чишүнең уңышлы юлларын таба белергә,

хезмәт сөючән, тырыш, игътибарлы булырга өйрәтү.


Кышкы көндә бер бабай
Урманга утынга барган.
Урман авызында аның,
Бияләе төшеп калган.
Бияләен эз-эзли ул
Тәмам хәлдән талган.

Үтеп барышлый төлке
Бияләйне тапкан.
«Нинди йомшак ,җылы!»-диеп
Эченә кереп яткан.
Бияләй телгә килгән
Ул аңа болай дигән:
-Мәсьәләмне чиш башта,
Аннан кереп ятарсың.
Дөрес җавап бирсәң,
Синдә приз отарсың.
Ләкин төлке баласы
Мәсьәлә чишә белми
Белер иде дә бәлки,
Ул бит мәктәпкә йөрми.
Менә бәлә нишләргә,
Без аңа ярдәм итик.
Бирелгән мәсьәләне
Әйдәгез бергә чишик.

**Самолет бер шәһәрдән икенчесенә 2 сәг. 25 мин. оча. Кире кайтканда шул араны 135 минутта очып үтә. Кайсы очракта самолет тизрәк очкан?**

Роза белән Алсуның икесенә бергә 28 сум,Роза белән Гөлиянең икесенә бергә 23 сум, Алсу белән Гөлиянең икесенә бергә 29 сум акчасы бар. Һәр баланың күпме акчасы бар?

Рәхмәт балалар,
Төлкегә булыштыгыз.
Ничек итсәк иттегез-
Бергәләп тырыштыгыз.

Әзме-күпме вакыт үткән
Тычкан йөгерә икән.
Каршысында зур гына
Биләйгә юлыккан.
“Керәм дә ятам”,- дигән.
-Тукта,- дигән биләй
Башта мәсьәләмне чиш,
Теләсә нишлә аннары
Калганы синең эш.
Тычкан мескен курыккан
Мәсьәлә авыр икән.
Әйдәгез бергәләшеп,
Без аңар ярдәм итик
Тычкан белән бергәләп
Тагын мәсьәлә чишик.



# Тычкан өчен мәсьәләләр

«Менә сезгә 3 таблетка дару, -ди доктор.
-Һәр ике сәгать саен берәр таблетка эчегез".
Күпме вакыттан соң соңгы таблетка эчелер?

- Балалар юлда 91 алтын тәңкәсе булган сандык табалар.Тәңкәләрне тигез итеп бүләләр.Ничә бала булган?Һәрберсенә ничә тәңкә тияр?
- Карл Гаусс 1дән алып 100 гә кадәр саннарны бик тиз исәпләп чыгарган. Ул ничек исәпләгән?


Рәхмәт балалар булыштыгыз, тычкан өчен тырыштыгыз!

Урман авызыннан куян йөгерә
Алдында зур гына
Бияләй күренә.
“Суыклар беткәнче яшим“,- дип
Үтмәкче була ул
Бияләй түренә.
Бияләй шунда телгә килә:
“Мәсьәләмне чиш башта
Аннан яшәрсең»,- дия.
Куян бик нык курыкты.
Сүз әйтә алмый, тотлыкты:
-Булы-шыгыз, ярдәм итег-ез…
Мәсьәләмне чишеп ките-гез.



# Куян өчен мәсьәләләр:

- Сигез таякның дүртесен сындыргач, ничә таяк кала?
- Бер математик , бик нык арып кичке сәгать 7 дә йокларга ятты. Будильникны иртәнге 9 га шалтыратырга куеп калдырды. Будильник шалтыраганга кадәр аңа күпме йокларга туры килер?

Җәнлекләр физкультминутта өчәрләп тезелгәннәр


Керпе, мәче, эт үзләрен:

Алдан 6нчы , арттан 3 нче рәттә икәнлекләрен белгәннәр.

Барысы ничә җәнлек физкульминут ясаган?




Ничек итсәгез иттегез,
тырыштыгыз
Авыр мәсьәләләрне чишәргә
Җәнлекләргә булыштыгыз!
Җәнлекләр бергәләшеп,
Җылыда йоклыйлар .
Булышкан балаларга
Һаман рәхмәт укыйлар.



Өйгә эш:карточкалар буенча кызыклы мәсьәләләр чишәргә.

Рәхмәт. Яшәгез рәхәттә,һәм хөрмәттә.